# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Таллы-Буләк  авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**23 ноябрь  2023 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 23 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары  нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Буләк  торак пункты  территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Таллы Бүләк авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Таллы Бүләк авылында юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Таллы Бүләк авылында койма, контейнер мәйданчыгы, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, контейнер сатып алу, контейнер мәйданчыгы төзү) ;
- Су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, насос сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия  165 гражданнар жыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 90.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 90, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Буләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә дөрес дип танырга.
2. Түбәнәге сораулар буенча карарны кабул ителгән дип таныргa:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Буләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Таллы Бүләк авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Таллы Бүләк авылында юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Таллы Бүләк торак пунктында койма, контейнер мәйданчыгы, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, контейнер сатып алу, контейнер мәйданчыгы төзү) ;
- Су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, насос сатып алу.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Карамалы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге башлыгы А.Р. Ногманов